**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30 июль 2019 года** **№124**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә төзекләндерү кагыйдәләре”нә үзгәрешләр кертү турында"**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советы 2019 елның 13 июнендәге 2 нче номерлы ачык тыңлаулар нәтиҗәсе нигезендә карар кабул итте:

1. “Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 июнендәге 55 номерлы карары белән расланган, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункты белән тулыландырырга:

«9.1. Сосновский борщевигының үсүенә юл куймау максатыннан, оештыру-хокукый формаларына карамастан, физик затлар (шәхси эшмәкәрләр) алар милкендә яки файдалануда булган җир кишәрлекләрендә Сосновский борщевигын юк итү буенча чаралар үткәрергә тиеш;

31нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«30 см артык калынлыкта кар катламнары барлыкка килүгә юл куймас өчен түбәләрне тышкы су бүлү белән кардан даими чистартып торырга кирәк,;

кагыйдәгә түбәндәге эчтәлекле 34.14 нче пункт өстәргә:

“34.14. физик затлар һәм юридик затлар (шәхси эшмәкәрләр) тарафыннан, аларның милкендә яки алардан файдалануда булган җир кишәрлекләрендә Сосновский борщевигын юк итү буенча чаралар үткәрү;”

кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 91.1 пункты белән тулыландырырга: «91.1. Автовокзалда, пристаньнарда, базарларда, паркларда, бакчаларда, ял итү зоналарында, мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният учреждениеләрендә һәм халык күпләп йөри торган башка урыннарда, урамнарда, торак йортларның подъездларында, тукталышларда, сәүдә объектларына керү юлында икедән ким булмаган чүп савытлары куелырга тиеш. Урналар объектларның милекчеләре, арендаторлары тарафыннан урнаштырыла. Чүпләрне чистарту аларны тотыру

буенча йортларның һәм территорияләрнең милекчеләре һәм арендаторлары тарафыннан башкарыла. Чүп савытларын буяу кирәк булганда башкарыла. Чүпләрне артык тутыру һәм пычрату рөхсәт ителми.»;

кагыйдәгә түбәндәге эчтәлекле 102.2 пункт өстәргә:

«102.2. Юлның машиналар йөри торган өлешен механикалаштырылган җыештыру, яуган кар , юл катламында 2,5-3,0 см биеклегендә булганда башланырга тиеш. Механикалаштырылган җыюштыру тәмамланганнан соң, юлның машиналар йөрү өлеше кардан һәм боз катламнарыннан тулысынча чистартылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 69 номерлы "«Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карарының 1.26 пунктын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 1;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкә авылы, Клуб ур., 14, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аны рәсми игълан итү (бастырып чыгару) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Советы Рәисе И.Х.Шиһабеев**